| | |
|---|---|
| **СОВЕТ<br>САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2020 Сарсак-Умга авылы № 3-2

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2019 елның 26 ноябрендәге 58-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2019 елның 26 ноябрендәге 58-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены

тарафыннан инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла торган җирлектә;»

1.2. 3.3 пунктында шушы сүзләрне төшереп калдырырга:

«муниципаль берәмлек башлыгы»;

1.3. 3.16 пунктында (13 нче беркетмә) сүзен (13 нче кушымта) сүзенә алмашытырырга; түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Көн тәртибе үзгәргән очракта, гражданнар җыенында тавыш бирү йомгаклары турында (нәтиҗәләре турында) Хисап комиссиясе беркетмәсе төзелә (14 нче кушымта)

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районының
Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының
22.10.2020 №3-2
карарына 14 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең _________торак пунктында гражданнар җыенының беренче, икенче (һ.б.) этап нәтиҗәләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (нәтиҗәләре турында) турында хисап комиссиясе беркетмәсе

«___» ____________ 20__ ел ______________________________

(торак пункт атамасы)

Территориядә гражданнар җыенының беренче, икенче (һ.б.) этап нәтиҗәләре

______________________________________________________________

(муниципаль берәмлек территориясе

______________________________________________________________

яки аның өлеше исеме)

Гражданнар җыены этапларын үткәрү датасы һәм вакыты:

1 этап - _________20___ ел, ____ сәг ____ минут,_________________________;

2 этап - _________20___ ел, ____ сәг ____ минут, _________________________;

Көн тәртибендәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены этапларында тавыш биргәндә тавышларны санау нәтиҗәсендә (беренчел мәсьәлә һәм эшләр күрсәтелә):

«20___ елда Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлегенең _______ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, _________ тыш (үзара салымнан азат ителә торган гражданнарның категорияләрен күрсәтергә) һәр балигъ булган кешедән ____ сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы?:

______________________________________________________________

___________________________________________________________»,

Хисап комиссиясе билгеләде:

1. Гражданнар җыенының уздырылган этаплары саны _______;

2. Гражданнар җыенының уздырылган этапларының хисап комиссияләре беркетмәләре саны _____;

3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә теркәлгән һәм җыен эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны __________;

4. Җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны ____________________;

5. Гражданнар җыенына кертелгән сорауга «РИЗА» дип җавап биргән тавышларының гомуми саны _____;

Көн тәртибендәге гражданнар җыенында үзгәрешләр булган очракта, көн тәртибенең үзгәртелгән мәсьәләсе күрсәтелә: җирле әһәмияттәге эшләрне башкаруга эшләр суммасы, исемлеге

6. «20___ елда Әгерже муниципаль районы авыл җирлегенең ________ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, __________ тыш (үзара салымнан азат ителә торган гражданнарның категорияләрен күрсәтергә) һәр балигъ булган кешедән _____ сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы?:

______________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________»,

7. Гражданнар җыенында кертелгән үзгәртелгән сорауга “РИЗА” дип җавап биргән тавышларның гомуми саны _____;

8. Гражданнар җыенында кертелгән үзгәртелгән сорауга “КАРШЫ” дип җавап биргән тавышларның гомуми саны _____.

Карар иттек: тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга. Көн тәртибендәге (үзгәртелгән) «20___ елда Әгерже муниципаль районы авыл җирлегенең ________ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, __________ тыш (үзара салымнан азат ителә торган гражданнарның категорияләрен күрсәтергә) һәр балигъ булган кешедән _____ сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы? -
_____________________________________________________________________________»
” мәсьәләсе буенча гражданнар җыены карары:

**кабул ителгән дип санарга.**

Халык җыены этапларының
хисап комиссияләре рәисләре:

| | |
|---|---|
| ____________ (имза) | ____________________ (имза расшифровкасы) |
| ____________ (имза) | ____________________ (имза расшифровкасы) |
| ____________ (имза) | ____________________ (имза расшифровкасы) |

Беркетмә төзелде «___» ______________ 20___ ел

1.4. 3.17 пунктында шушы сүзләрне төшереп калдырырга:
«авыл җирлеге башлыгы кул куйган»;
1.5. 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль норматив хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы яисә җыенда башка рәислек итүче зат тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.»;

1.6. 4.5. пуктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«(үзара салым үрнәгендә 14 нче кушымта үрнәге)»;

Нигезләмәшә түбәндәге эчтәлекле 15 нче кушымтаны өстәргә:

Татарстан Республикасы<br>
Әгерҗе муниципаль районының<br>
Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының<br>
22.10.2020 №3-2<br>
карарына 15 нче кушымта

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы

«Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең ___________ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

__________ 20__ ел №___

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «__» ______ 20___ елның 00 сәг 00 минутта, «__» ______ 20___ елның 00 сәг 00 минутта этаплап узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде ________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә ___ гражданнар җыенында катнашучылар кертелгән, сайлауда катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны ___, бу ____ %тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен ____ гражданнар җыенында катнашучы; «КАРШЫ» позициясе өчен ____ гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең ___________ торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. ______елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге _____________ территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән ______ сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

______________________________________________________________________________

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________________________________
______________________________________________________________________________

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Сарсак-Умга авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Т.С. Николаева